ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабрь 2019ел № 6497

Башкарма комитетның «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5951 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының нигезләмәләрен үзгәртү һәм үз көчен югалтуын тану турында» 2019 елның 4 июлендәге 858 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5951 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3271 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 3597 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6597 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын тормышка ашыруның кайбер мәсьәләләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тормышка ашыру кагыйдәләрен раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

2) Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә дәүләт торак

сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 1.4 пунктының 5 абзацында «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын тормышка ашыруның кайбер мәсьәләләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тормышка ашыру кагыйдәләрен раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.3 пунктының 2 баганасына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«гражданны ведомство максатчан программасында катнашучы дип тану яисә танудан баш тарту турында карар»;

- 2.5 пунктының икенче баганасындагы сигезенче абзацта «Белешмә» сүзен «Мәгълүматлар» сүзенә алмаштырырга;

- 2.5 пунктының икенче баганасындагы 13 абзацта «төп чарасын» сүзләрен «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 пунктының икенче баганасындагы 15 абзац үз көчен югалткан дип танырга;

- 3.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге пунктчаны өстәргә:

«3.5.21. Район хакимияте белгече гражданны ведомство максатчан программасында катнашучы дип тану яисә танудан баш тарту турында карарны җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданны ведомство максатчан программасында катнашучы дип тану яисә танудан баш тарту турында гариза бирүчегә җибәрелгән карар.».

- 3.6.1 пунктта «сертификат бланклары алган датадан башлап 2 айлык срокта» сүзләре үз көчен югалткан дип танырга;

- 2 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 3 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 4 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 13 декабрендәге
6497 номерлы карарына
1 нче кушымта

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү буенча административ регламентка
2 нче кушымта

____________________________________________
(Россия Федерациисе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы, бүлекчә җитәкчесенә, граждан торак урыннарына мохтаҗ сыйфатында (торак урыны сатып алуга социаль түләү алуга хокуклы сыйфатында) исәптә торучы Байконур шәһәре хакимияте башлыгына)

__________________________ адресы буенча яшәүче
(почта адресы)
граждан ____________________________________
(исеме,фамилиясе, атасының исеме (булганда)

ГАРИЗА (РАПОРТ)

Мине,
_____________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы)
_____________________________________________________________________________,
(Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, әлеге документ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән),
мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ______________________, «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасында катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тормышка ашыру кагыйдәләрен раслау хакында» 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тормышка ашыру кагыйдәләренең 5 пунктының ____ пунктчасы нигезендә дәүләт торак сертификаты белән таныклана торган торак урыны сатып алу өчен социаль түләү алырга хокукым бар.

Сайлап алынган яшәү урыны (Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы "а", "б", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан гына күрсәтелә)

______________________________________________________________________________.

(Россия Федерациясе субъектының исеме)

«_____» _______ ______ елдан башлап торак урыннарына мохтаҗ сыйфатында (торак урыны сатып алу өчен социаль түләү алуга хокуклы сыйфатында) исәптә торам.

Гаилә составы:

хатыным (ирем) ________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы)

______________________________________________________________________________,

(Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, әлеге документ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ___________________;

балаларым:

улым (кызым) __________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы)

______________________________________________________________________________,

(Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, әлеге документ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ___________________;

ата-аналарым:

атам (анам) ____________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы)

______________________________________________________________________________,

(Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, әлеге документ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ___________________.

Моннан тыш, минем белән гаиләнең башка әгъзалары яши:

______________________________________________________________________________,

туганлык дәрәҗәсе, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы)

______________________________________________________________________________,

(Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, әлеге документ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ___________________.

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сетификаты белән таныклана торган торак урыны сатып алу өчен социаль түләү алу тәртибе һәм шартлары турында таныштым.

Минем тарафтан гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

______________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры (булганда), кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры (булганда), кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры (булганда), кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________________.

(документның исеме һәм номеры (булганда), кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

________________________________________ ____________ ____________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) (имзасы) (дата)

Мин һәм минем гаилә әгъзалары «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасында катнашу максатында, минем персональ мәгълүматларны һәм минем гаилә әгъзаларының персональ мәгълүматларын автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча эшкәртүгә, атап әйткәндә, күрсәтелгән ведомство максатчан программасында катнашу һәм миңа һәм минем гаилә әгъзаларына дәүләт торак сертификаты белән таныклана торган торак урыны сатып алуга социаль түләү алу өчен минем тарафтан

________________________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы, бүлекчә, Байконур шәһәре хакимияте исеме)

тапшырылган мәгълүматлар белән «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законның 3 статьясының 3 пунктында каралган гамәлләр башкаруга ризалыгыбызны бирәбез.

Әлеге ризалык тиешле мәгълүматны яки күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган документларны саклау сроклары чыкканчыга кадәр бирелә.

| | | |
|---|---|---|
| __________________________________ | __________ | __________ |
| (гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | (имзасы) | (дата) |
| __________________________________ | __________ | __________ |
| (гариза бирүче гаиләсенең балигъ булган әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | (имзасы) | (дата) |
| __________________________________ | __________ | __________ |
| (гариза бирүче гаиләсенең балигъ булган әгъзасының ) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда | (имзасы) | (дата) |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2019 елның 13 декабрендәге
6497 номерлы карарына
2 нче кушымта

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү буенча административ регламентка
3 нче кушымта

___________________________________________
(җирле үзидарә органы, бүлекчә җитәкчесенә, Байконур шәһәре хакимияте башлыгына)
адресы буенча яшәүче ___________________________
___________________________________________
(яшәү урыны буенча теркәлү һәм фактта яшәү урыны адресы)

граждан ___________________________________
(ф.и.а.и)
телефон ___________________________________

ГАРИЗА (РАПОРТ)

Миңа, _____________________________________________________________________,
(ф.и.а.и.)
паспорт _____________ _____________________________________________________
_______________________ бирелгән, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры_____________________, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасы буенча
_______________________________________________________________________________
(чараның исеме)
чарасы кысаларында ___________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.
(«территориядә» һәм Россия Федерациясе субъектының исеме күрсәтелә, ябык административ-территориаль берәмлекләрдән күчерелергә тиешле гражданнардан тыш, алар өчен «ябык административ-территориаль берәмлек чикләреннән читтә» курсәтелә һәм «Байконур» комплексы территориясеннән күчерелелергә тиешле гражданнардан тыш, алар өчен «Россия Федерациясе территориясендә» күрсәтелә)
торак урыны алуга дәүләт торак сертификаты бирүегезне сорыйм.

Гаилә составы:
хатыным (ирем) ______________________________________________________________,
(ф.и.а.и., туу датасы)
«____» ______ ________ ______________________________________ бирелгән, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ______________________,
______________________________________________________________ адресы буенча яши;
(яшәү урыны буенча теркәлү һәм фактта яшәү урыны адресы)

балаларым:

__________________________________________________________________________________,
(туганлык дәрәҗәсе, ф.и.а.и атасының исеме, туу датасы)
(паспорт (туу турында таныклык) «____» _______ _____ ____________ бирелгән, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ______________________,
_______________________________________________________________адресы буенча яши;
(яшәү урыны буенча теркәлү һәм фактта яшәү урыны адресы)

ата-аналарым:

__________________________________________________________________________________,
(туганлык дәрәҗәсе, ф.и.а.и.)
паспорт «____»________ _______ ______________________________ бирелгән, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ______________________,
_______________________________________________________________адресы буенча яши;
(яшәү урыны буенча теркәлү һәм фактта яшәү урыны адресы)

Моннан тыш, минем белән гаиләнең башка әгъзалары яши:

__________________________________________________________________________________,
(туганлык дәрәҗәсе, ф.и.а.и., туган көне),
паспорт «____» ______ ________ ______________________________бирелгән, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетның иминият номеры ______________________.

Торак урыннарына мохтаҗ (торак урыны сатып алу өчен социаль түләү алуга хокукы булган, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ) сыйфатында «_____» _______ ___________ елдан башлап __________________________ исәптә торам.
(исәпкә кую урыны)

Хәзерге вакытта мин һәм минем гаилә әгъзалары Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү өчен торак урынга ____________________________.
(«ия түгел» яки «ия» күрсәтелә)

Минем һәм (яки) минем гаилә әгъзалары тарафыннан социаль найм килешүләре буенча биләнә торган һәм (яки) минем һәм (яки) минем гаилә әгъзаларының милекчелек хокукындагы торак урыннар булу турында мәгълүматлар:

| т/с | Фамилиясе исеме, атасының исеме | Торак урын урнашкан урынның почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв. метр | Файдалану нигезе (социаль найм килешүе яки милекчелек хокукы нигезендә), килешүнең датасы һәм реквизитлары, милекчелек хокукы турында таныклык реквизитлары (Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы язма нигезендә милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу номеры һәм датасы) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Минем һәм минем гаилә әгъзалары тарафыннан торак урыны сатып алу яки төзү өчен федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан яки җирле бюджетаттан акча

__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________.
(«алынмады» яки «алынды» күрсәтелә, акча алынган очракта түләүне гамәлгә ашырган орган, түләү датасы һәм суммасы күрсәтелә)

Минем һәм минем гаилә әгъзалары тарафыннан торак урыннары белән, биләнә торган торак урыннарының күләмен киметүгә яки аларны тартып алуга китергән гамәлләр һәм гражданлык-хокукый килешүләр ____________________________________________________.
(«башкарылмады» яки «башкарылды» күрсәтелә)

Торак урыннары белән, биләнә торган торак урыннарының күләмен киметүгә яки аларны тартып алуга китергән гамәлләр һәм гражданлык-хокукый килешүләр турында мәгълүматлар (әлеге торак урынны дәүләт яки муниципаль милеккә түләүсез тартып алу очрагыннан тыш):

| т/с | Фамилиясе исеме, атасының исеме | Торак урын урнашкан урынның почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв. м | Биләнә торган торак урынның күләмен киметүгә яки тартып алуга китергән гамәл (гражданлык-хокукый килешүе) һәм күрсәтелгән гамәлне (килешүне) башкару фактын раслаучы документларның реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Мин һәм (яки) минем гаилә әгъзалары әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйбыз. Тапшырылган мәгълүматларга федераль башкарма хакимият органнарында (федераль дәүләт органнарында), Федераль салым хезмәтен, миграция өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча федераль башкарма хакимият органын, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтен кертеп, тикшерү үткәрүгә, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен рөхсәт бирәбез.

Мин, ____________________________________________________________,

(ф.и.а.и..)

минем тарафтан тапшырылган мәгълүматларда һәм гаризага теркәлгән документларда дөреслеккә туры килмәгән һәм дәүләт торак сертификаты алу өчен нигез булып тормаган мәгълүматлар ачыкланган очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тартылу турында кисәтелдем.

Дәүләт торак сертификаты алу һәм аннан файдалану шартлары белән таныштым, аларны үтәргә риза һәм йөкләмә алам.

______________________________ ______________ "__" ______________ 20__ ел.

(гариза бирүченең ф.и.а.и.) (имза)

Гаилә әгъзалары гариза белән риза:

________________________________________ ____________________

(ф.и.а.и.) (имза)

________________________________________ ____________________

(ф.и.а.и.) (имза)

________________________________________ ____________________

(ф.и.а.и.) (имза)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

____________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

____________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

____________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

____________________________________________________________.

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Искәрмәләр:

1. Гаиләнең балигъ булмаган һәм (яки) хокукка сәләтсез әгъзаларының гариза белән ризалыгын белдереп, аларның законлы вәкилләре (опекуннары) имза куя.

2. Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының имзалары дәүләт сертификаты бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының (бүлекчәнең, Байконур шәһәре хакимиятенең) вәкаләтле вызыйфаи затының имзасы һәм күрсәтелгән җирле үзидарә органының (бүлекчәнең, Байконур шәһәре хакимиятенең) мөһере белән раслана.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова